ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

14.05.2018 | г. Иннополис | № 31

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары һәм муниципаль органнар функцияләрен, шул исәптән территориаль органнар һәм ведомство буйсынуындагы казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләүнең гомуми кагыйдәләре турында» 2014 елның 13 октябрендәге 1047 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәренең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләрне раслау турында» 2018 елның 2 февралендәге 7 номерлы Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карары, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре муниципаль органнары, муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 18 апрелендәге 25 номерлы карары нигезендә Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре муниципаль казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында аны раслаган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

3. 7 көн эчендә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмати сайтына (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/) урнаштырырга .

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р. Р. Шагалиев